| СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ**
**29.10.2018**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 332**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәнфәгатьләрендә гавами сервитутларны билгеләү һәм туктату һәм аны билгеләгән өчен тиешле түләү тәртибе турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, Татарстан Республикасы Җир кодексының 5 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 16 статьясы һәм «Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә гавами серутовитны билгеләү һәм туктату тәртибе турында» 2011 елның 12 августындагы 660 номерлы карарының 2 пункты нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәнфәгатьләрендә гавами сервитутлар билгеләү һәм туктату тәртибен (1 нче кушымта) расларга.
2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәнфәгатьләрендә гавами сервитутларны билгеләгән өчен тиешле түләү тәртибен (2 нче кушымта) расларга.
3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Д.А.Сапожниковка йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль**
**районы Башлыгы,**
**Советы рәисе** **А. В. Тыгин**

Зеленодольск муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәнфәгатьләрендә гавами сервитутларны билгеләү һәм туктату һәм аны билгеләгән өчен тиешле түләү тәртибе турында» 2018 елның 29 октябрендәге 332 номерлы карарына 1 нче кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘНФӘГАТЬЛӘРЕНДӘ ГАВАМИ СЕРВИТУТЛАРНЫ БИЛГЕЛӘҮ ҺӘМ ТУКТАТУ ТӘРТИБЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1. Әлеге тәртиптә Россия Федерациясе җир законнары нигезендә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәнфәгатьләрендә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан җир кишәрлекләренә карата гавами сервитутларны билгеләү һәм туктату процедуралары җайга салына (алга таба - гавами сервитут).

2. Гавами сервитут Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәнфәгатьләре объектив гамәлдә булган хәлләр аркасында аны билгеләмичә тәэмин итеlә алмаган һәм чит җир кишәрлегеннән аны хокукка ия булучыдан (милекчедән, җир биләүчедән, җирдән файдаланучыдан) тартып алмыйча файдалану хокукын күздә тоткан очракларда билгеләнә.

3. Гавами сервитут түбәндәгеләр өчен билгеләнә:

1) җир кишәрлеге аша үтү яисә чыгу;

2) коммуналь, инженерлык, электр һәм башка линияләрне һәм челтәрләрне, шулай ук транспорт инфраструктурасы объектларын ремонтлау максатларында җир кишәрлегеннән файдалану;

3) җир кишәрлегендә ызан һәм геодезик билгеләр һәм аларга килү юллары урнаштыру;

4) җир кишәрлегендә дренаж эшләрен башкару;

5) су объектларыннан су ресурсларын алу (тартып алу);

6) авыл хуҗалыгы терлекләрен җир кишәрлеге аша куып чыгару;

7) җирле шартларга һәм гореф-гадәтләргә туры килгән срокларда билгеләнгән тәртиптә җир кишәрлекләрендә печән чабу, авыл хуҗалыгы хайваннарын көтү;

8) аучылык һәм балыкчылык максатларында җир кишәрлегеннән файдалану;

9) эзләнү, тикшеренү һәм башка эшләр башкару максатларында җир кишәрлегеннән вакытлыча файдалану;

10) яр буе полосасына ирекле керү мөмкинлеге.

4. Гавами сервитутлар дәүләт кадастр исәбенә узган җир кишәрлекләренә карата билгеләнә.

5. Гавами сервитут яңа җир кишәрлеген формалаштырганда аны бирү чорында да, шулай ук элек, гавами сервитут урнаштыру ихтыяҗы барлыкка килгәч, формалаштырылган җир кишәрлегенә карата да билгеләнә.

## II. ГАВАМИ СЕРВИТУТНЫ БИЛГЕЛӘҮ ҺӘМ ТУКТАТУ ТӘРТИБЕ

6. Гавами сервитут билгеләү турындагы карар Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты тарафыннан кабул ителә.

7. Гавами сервитутны билгеләү инициаторлары булып федераль башкарма хакимият органнары яки Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, аларның оештыру-хокукый формасына һәм милек формасына бәйсез рәвештә, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар, аларның эшен һәм тормыш эшчәнлеген тәэмин итү өчен гавами сервитутны билгеләү кирәк булган очракта, шулай ук җир кишәрлекләре милекчеләре, җир хуҗалары һәм җирдән файдаланучылар, әгәр аларның җир кишәрлегеннән файдалану хокукы Зеленодольск муниципаль районы мәнфәгатьләрендә файдалану нәтиҗәсендә чикләнгән булса.

8. Гавами сервитут билгеләү турындагы үтенечнамә «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесенә кертелә.

9. Гавами сервитут билгеләү турындагы үтенечнамәдә түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

1) гавами сервитут урнаштыру күздә тотыла торган җир кишәрлеге турында: урнашу урыны, кадастр номеры, мәйданы, җирләр категориясе, рөхсәт ителгән файдалану, йөкләүләр;

2) гавами сервитут билгеләү максаты һәм аны билгеләү кирәклеген нигезләү турында;

3) гавами сервитутның тәкъдим ителә торган вакыты турында.

10. Гавами сервитут булдыру турындагы үтенечкә юридик зат җитәкчесе (юридик затлар җитәкчеләре), шәхси эшмәкәр (индивидуаль эшмәкәрләр) һәм (яки) физик зат (физик затлар) ,түбәндәгеләрне күрсәтеп, кул куя:

1) юридик зат өчен - юридик затны дәүләт теркәве белешмәләренең тулы исеме;

2) шәхси эшкуар өчен - гражданның шәхси эшкуар буларак дәүләт теркәве күрсәткечләренең һәм фамилиясе, исеме, атасының исеме;

3) физик зат өчен - фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт мәгълүматлары, яшәү урыны, салым түләүченең индивидуаль номеры.

11. Гавами сервитутны билгеләү гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып башкарыла.

12. Гавами сервитутны билгеләү турындагы карарда түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

1) гавами сервитут билгеләнгән җир кишәрлеге турында: урнашкан урыны, кадастр номеры, мәйданы, җирләрнең категориясе, рөхсәт ителгән файдалану, шулай ук кызыксынучы затлар тарафыннан җир кишәрлегеннән чикләнгән файдалану хокукын гамәлгә ашыру өчен аерымланырга тиешле җир кишәрлеге өлеше турында белешмәләр;

2) тиешле җир кишәрлегенең милекчесе, җирдән файдаланучысы яисә җир хуҗасы турында: юридик затның тулы исеме, физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме;

3) гавами сервитутның гамәлдә булу срогы турында;

4) гавами сервитут өчен түләү күләме турында, әгәр ул билгеләнгән булса.

13. Гавами сервитут билгеләү турындагы карарның күчермәсе, кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә, ул билгеләнгән җир кишәрлегенең хокукый хуҗасына һәм гавами сервитут урнаштыру белән кызыксынган затка җибәрелә.

14. Гавами сервитут «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» Федераль закон нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиеш.

Гавами сервитутны дәүләт теркәвенә алуны «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесе башкара.

15. Гавами сервитут билгеләү җир кишәрлеген файдалану мөмкин булмавына китергән очракта, җир кишәрлеге милекчесе, җир хуҗасы, җир биләүче, җирдән файдаланучы, гавами сервитут билгеләү турында карар кабул иткән Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан зыянны каплау яки зыянны каплап шундый ук җир кишәрлеге бирүне таләп итәргә хокуклы, шул исәптән сатып алу юлы белән дә.

Әгәр гавами сервитут билгеләү җир кишәрлеген кулланууда җитди кыенлыклар тудыра икән, аның хуҗасы тиешле түләүне таләп итәргә хокуклы.

16. Зеленодольск муниципаль районы мәнфәгатьләрен тәэмин итүче гавами сервитутлар билгеләү һәм туктату, шул исәптән гавами сервитутны дәүләт теркәвенә алу, җир кишәрлегенең кадастр паспортына үзгәрешләр кертү, җир кишәрлегенең хокук иясенә зыянны каплау белән бәйле чыгымнарны финанслау Зеленодольск муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Гавами сервитутны билгеләү мәсьәләсе буенча җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны финанслау, аны билгеләү инициаторы (инициаторлары) акчалары хисабына, шул исәптән гавами сервитутны билгеләү турында үтенечнамә юллаучы затлар акчалары хисабына башкарыла.

17. Гавами сервитут билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвеннән соң үз көченә керә.

Гавами сервитут Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан гавами сервитутының билгеләнгән гамәлдә булу срогы тәмамланганнан соң, ул билгеләнгән җәмәгать ихтыяҗлары булмаган очракта, гавами сервитутын билгеләүгә охшаш тәртиптә яки суд карары нигезендә, җәмәгать сервитутын гамәлдән чыгару турында карар кабул итү белән туктатыла.

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының гавами сервитутны туктату турындагы карары, шул исәптән вакытыннан алда, күчемсез милеккә хокукларның һәм аның белән гавами сервитутны туктату турындагы килешүләрнең бердәм дәүләт реестрына язма кертелгән көннән үз көченә керә.

## III. ГАВАМИ СЕРВИТУТЛАР УРНАШТЫРУ БУЕНЧА ГАВАМИ ТЫҢЛАУЛАР ҮТКӘРҮ ТӘРТИБЕ

18. Гавами тыңлаулар үткәрү Татарстан Республикасының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгатьчелек белән фикер алышуларны) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

Зеленодольск муниципаль
районы Советының
«Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль
районы мәнфәгатьләрендә
гавами сервитутларны
билгеләү һәм туктату һәм
аны билгеләгән өчен
тиешле түләү тәртибе
турында» 2018 елның 29
октябрендәге 332 номерлы
карарына 2 нче кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘНФӘГАТЬЛӘРЕНДӘ ГАВАМИ СЕРВИТУТНЫ БИЛГЕЛӘҮ ҺӘМ ТИЕШЛЕ ХАКНЫ ТҮЛӘҮ ТӘРТИБЕ

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге тәртип Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан җир кишәрлекләренә билгеләнгән гавами сервитутны (алга таба - сервитут) билгеләү һәм тиешле хакны түләү өчен билгеләнә.

1.2. Әлеге Тәртип кысаларында сервитут өчен тиешле хак - җир кишәрлеге хуҗасына Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан сервитутны билгеләү нәтиҗәсендә аның хокуклары чикләнү сәбәпле, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәнфәгатьләрен тәэмин итү өчен сервитут билгеләгәндә түләнә торган, чит җир кишәрлегеннән файдалану өчен түләү.

1.3. Сервитут өчен тиешле хакны түләү бер тапкыр тулы күләмдә түләнгәндә бер тапкыр бирелә торган характерда булырга мөмкин, һәм периодик характер, түләү сервитут билгеләнгән вакыт дәвамында өлешләп күп тапкырлар түләнә икән.

1.4. Сервитут өчен тиешле хакны түләү чыгымнарын финанслау Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына башкарыла.

Сервитут өчен билгеләнгән хакны түләү Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының бюджет акчаларын бүлеп бирүче булып Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты тора.

1.5. Сервитут өчен түләүне гамәлгә ашыру турында карар кабул итүдән баш тартуны сервитут билгеләнгән җир кишәрлеге хуҗасы тарафыннан судта шикаять бирелергә мөмкин.

## 2. СЕРВИТУТ ӨЧЕН ТИЕШЛЕ ХАКНЫҢ КҮЛӘМЕН БИЛГЕЛӘҮ

2.1. Сервитут өчен еллык тиешле түләүнең күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$СП = Р_{ап} \times К_{у} \times П_{зу},$$

биредә:

СП - сервитут өчен еллык тиешле түләүнең күләме,сумнарда ;

- $Р_{ап}$ Дәүләт (муниципаль) милкендәге җир кишәрлекләре өчен еллык аренда түләвенең уртача күләме, гектар өчен сум;

$К_{у}$ -сервитут билгеләү нәтиҗәсендә җир кишәрлеге милекчесенең хокукларын чикләүгә бәйле рәвештә зыян коэффициенты,%;

$П_{зу}$ - сервитут билгеләнгән җир кишәрлегенең мәйдан зурлыгы - гектар.

Зыяннар коэффициенты күләме $К_{у}$ формула буенча исәпләнә:

$$К_{у} = (С_{р} + Р)/100\% + 1,$$

биредә:

$С_{р}$ - сервитут билгеләү вакытына гамәлдә булган Россия Федерациясе Үзәк банкын рефинанслау ставкасы, %;

Р - рисклар суммасы, %.

Риск суммасы Р түбәндәге таблица буенча, территориясендә җир кишәрлеге урнашкан Зеленодольск муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлектә яшәүче халык санына бәйле рәвештә, билгеләнә:

Таблица

| Җирлек халкы саны | Рисклар суммасы Р, % |
|---|---|
| 2 меңгә кадәр кеше | 5,0 |
| 2 дән 5 меңгә кадәр кеше | 5,5 |
| 5 меңнән 10 меңгә кадәр кеше | 6,0 |
| 10нан 20 меңгә кадәр кеше | 6,5 |
| 20 меңнән артык кеше | 7,0 |

2.2. Сервитлар билгеле бер срокка билгеләнгән очракта, сервитут өчен туры килерлек түләү күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$СП_{сроч} = СП / 12 \times Т ,$$

биредә:

$СП_{сроч}$ - билгеле бер вакытка билгеләнгән сервитут өчен тиешле түләү күләме, сум;

СП - сервитут өчен еллык тиешле түләүнең күләме,сумнарда ;
Т - сервитут гамәлдә булган айлар саны.

## 3. СЕРВИТУТ ӨЧЕН ТИЕШЛЕ ХАКНЫ ТҮЛӘҮ ТӘРТИБЕ

3.1. Сервитут күчемсез милеккә хокукларның бердәм дәүләт реестрында теркәлгәннән соң һәм аның белән килешүләр төзегәннән соң, сервитут белән чикләнгән җир кишәрлеге хуҗасы, әгәр аны билгеләү җир кишәрлеген куллануда җитди кыенлыклар тудырса, сервитут өчен тиешле түләүне таләп итәргә хокуклы.

3.2. Сервитут өчен тиешле түләүне алу өчен, сервитут белән чикләнгән җир кишәрлеге хуҗасы (алга таба - гариза бирүче) Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына тиешле гариза белән мөрәҗәгать итә.

Гаризада сервитут билгеләнгән җир кишәрлегенең кадастр номеры, аның урнашу урыны, мәйданы, җирләрнең категориясе, рөхсәт ителгән файдалану, сервитут билгеләнүгә бәйле рәвештә җир кишәрлеген куллануда җитди кыенлыклар тудыручы чикләүләр һәм сәбәпләр күрсәтелә.

Гаризага мөрәҗәгать итүченең - физик затның шәхесен раслаучы документларның күчермәләре, яисә индивидуаль эшкуарларның Бердәм дәүләт реестрыннан - шәхси эшмәкәрләр өчен яисә юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә - юридик затлар өчен, җир кишәрлегенең кадастр паспорты, җир кишәрлегенә милек хокукын раслаучы документларның күчермәләре кушымта итеп бирелә.

3.3. Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитеты гариза кергән көннән алып җиде көн эчендә кергән документларны карый, сервитут өчен тиешле түләүне әлеге Тәртипнең 2 бүлеге нигезендә исәпләп чыгара яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге Тәртипнең 3.2 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган исемлеге тапшырылган яисә тәкъдим ителгән документлар арасында каршылыклар булган очракта, документларны мөрәҗәгать итүчегә кайтара.

3.4. Сервитут билгеләнгән җир кишәрлеге хуҗасының исәп-хисап счетына сервитут өчен түләүгә билгеләнгән акчалар Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының шәхси счетыннан күчерелә.

3.5. Сервитут өчен тиешле түләү күләме Россия Федерациясе Гражданлык һәм Җир кодексы белән билгеләнгән очракларда, әлеге Тәртипнең 3 бүлеге белән билгеләнгән тәртиптә, сервитут билгеләнгән җир кишәрлеге хуҗасының гаризасы нигезендә, билгеләнгән срок дәвамында үзгәртелергә мөмкин.